| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 373 “29” 06 **2022 ел**

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджетыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм Спас муниципаль районында алты һәм аннан күбрәк баш савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан күбрәк баш савым сыеры булган гражданнарга савым аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 7 мартындагы 151 номерлы карары (2021 елның 14 гыйнварындагы 14 номерлы үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 1662 номерлы РФ Хөкүмәте карары нигезендә, ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджетыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында алты һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019

елның 7 мартындагы 151 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм Спас муниципаль районында алты һәм аннан да күбрәк савым сыеры, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында алты һәм аннан күбрәк баш савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы (2021 елның 14 гыйнварындагы 14 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында:

1.1. 5 бүлектә «контроль» сүзен «контроль (мониторинг)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.6 пунктта «субсидия алучылар» сүзләрен тиешле килештә «сайлап алуда катнашучылар» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында урнаштырырга (/http:pravo.tatarstan.ru).

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В. А. Осокин